КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 сентябрь г.Казань № 1191

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче; 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы; 2016 ел, 13 август, 557 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1050 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 912 нче; 2018 ел, 12 май, 352 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 956 нчы; 2019 ел, 15 гыйнвар, 2 нче; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 833 нче; 2020 ел, 9 ноябрь, 1001 нче; 2021 ел, 26 февраль, 102 нче; 2021 ел, 21 июль, 623 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1139 нчы; 2022 ел, 25 июль, 714 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1011 нче; 2022 ел, 16 декабрь, 1351 нче; 2023 ел, 4 июль, 789 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

3 пунктта:

икенче абзацта «аппаратта» сүзен «үзәк аппаратта» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «аппаратта» сүзләрен «үзәк аппаратта» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «территориаль бүлекләрдә» сүзләрен «территориаль органнарда» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «2011 елга, 2012 һәм 2013 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга;

6, 7 һәм 9 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәдә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

7.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгы:

бер башлыклылык принципларында Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

дәүләт хакимиятенең башка органнары, шулай ук дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар белән хезмәттәшлек иткәндә, ышанычнамә кәгазеннән башка, Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе исеменнән эш алып бара;

Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе эшен оештыра;

Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе тарафыннан үз компетенциясенә керә торган функцияләрне һәм вәкаләтләрне үтәү өчен һәм Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе тарафыннан кабул ителә торган хокук актларның һәм ул гамәлгә ашыра торган оештыру-күрсәтмә органнарының законлы булуы өчен шәхси җавап бирә;

Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның вазыйфаи бурычларын билгели, аларга карата кызыксындыру чараларын куллана һәм дисциплинар җәза чараларын белдерү;

чираттагы елга расланган сметаларда билгеләнгән акча чикләрендә Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең финанс эшчәнлеген оештыра, финанс һәм исәпкә алу дисциплинасын үтәүне тәэмин итә, финанс документларына кул куя, шартнамәләр төзи, ышанычнамәләр бирә, закон белән билгеләнгән тәртиптә мөлкәт һәм бүлеп бирелгән ассигнованиеләр белән эш итә, өстәмәләр, өстәмә

түләүләр, премияләр һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләр күләмен билгели;

Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенә беркетелгән мөлкәт (шул исәптән яңа сатып алынган мөлкәт, җиһаз һәм башка матди чаралар) белән оператив идарә итүне гамәлгә ашыра;

янгынга каршы куркынычсызлыкны, шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан хезмәтне саклау, куркынычсызлык техникасы һәм җитештерү санитариясе таләпләрен үтәүне тәэмин итә;

эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслый;

Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе хезмәткәрләре квалификациясен күтәрүне оештыра;

аеруча аерылып торган хезмәткәрләргә билгеләнгән тәртиптә мактаулы исемнәр бирүгә һәм дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә. Матди һәм мораль бүләкләү чараларын күрә, билгеләнгән тәртиптә ведомство бүләкләрен гамәлгә куя, әлеге бүләкләр турындагы нигезләмәләрне һәм аларның тасвирламасын раслый, хезмәткәрләрне ведомство бүләкләре белән бүләкли;

Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен (вазыйфаи регламентларын) раслый;

дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә дәүләт граждан хезмәте узуга бәйле мәсьәләләрне хәл итә;

федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән үз компетенциясе чикләрендә боерыклар, инструкцияләр, нигезләмәләр һәм кагыйдәләр чыгара;

Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең структур бүлекчәләр башлыгы урынбасары, җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәялүне гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

7.5 пунктта «Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе аппараты һәм аның район һәм шәһәр бүлекләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең үзәк аппараты һәм аның территориаль органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7.6 пунктта «Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең шәһәр

һәм район бүлекләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең Үзәк аппараты һәм территориаль органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7.9 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасының Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе, Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелегенең район һәм шәһәр бүлекләре аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсенең үзәк аппараты һәм территориаль органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин